**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 12 маендагы 1629 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2022 елның 21 апрелендәге 1194 номерлы «Казан шәһәре территориясендә самокатлар һәм велосипедлар прокаты пунктларын урнаштыру схемасын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәре территориясендә шәхси мобильлек чараларын һәм велосипед кулланууны үстерү проектын гамәлгә ашыру, шулай ук самокат һәм велосипедларны дислокацияләү урыннарын төгәлләштерү максатыннан:

1. **Карар бирәм**:

1.1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 21 апрелендәге 1194 номерлы «Казан шәһәре территориясендә самокатлар һәм велосипедлар прокаты пунктларын урнаштыру схемасын раслау турында»гы карарының кушымтасына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 20 апрелендәге 1134 номерлы, 2023 елның 19 маендагы 1403 номерлы, 2023 елның 31 августындагы 2515 номерлы, 2024 елның 1 августындагы 3252 номерлы, 2025 елның 17 маендагы 1535 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 95, 253, 332, 350, 372, 390, 426, 492, 555, 662, 742, 759, 786, 790, 835, 847, 904, 915, 1138, 1158, 1198, 1275, 1286 юлларны төшереп калдырып, үзгәрешләр кертергә;

1.2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. Казан шәһәре Думасы аппаратының мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) юл хәрәкәтендә катнашучыларга массакүләм мәгълүмат чаралары, социаль медиаресурслар аша самокатларны прокатка бирү пунктларын урнаштыру урыннары турында хәбәр итәргә **тәкъдим итәм**.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**